КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.12.2025 № 856-П

Татарстан Республикасы, Спас районы, Болгар шәһәре адресы буенча урнашкан, ачыкланган «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал, ск. В.М.Маликов» мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1982 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү, аның территориясе чикләрен һәм аны саклау предметын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2025 елның 5 декабрендәге уңай бәяләмәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Спас районы, Болгар шәһәре адресы буенча урнашкан, ачыкланган «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал, ск. В.М.Маликов» мәдәни мирас объектын Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, (объект төре – һәйкәл) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертергә.

2. Әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау предметын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.


5. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2025 елның 22 декабрендәге 856-П номерлы боерыгына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты
**территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре картасы (схемасы)




Масштабы 1:1000

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| (кызыл сызык) | - мәдәни мирас объекты территориясе чиге |
| 1● | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| (кызыл квадрат) | - мәдәни мирас объекты |
| (яшел сызык) | - КМБДР белешмәләре буенча җир кишәрлекләре чикләре |
| (зәңгәр сызык) | - КМБДР белешмәләре буенча кадастр кварталы территориясе |
| **16:37:010503:44** | - җир кишәрлегенең кадастр номеры |

Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **текстлы тасвирламасы**

Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә уза:

| Чикне узу | | Чикне узуның тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | 16:37:000000:633 җир кишәрлегенең кадастр чигенең көньяк-көнчыгыш почмагы янында «Геройлар аллеясы»ның иң азагында урнашкан 1 ноктасыннан төньяк-көнчыгыш юнәлештә утыртылган агачлар буйлап 16,45 м ераклыкка 2 ноктасына кадәр; |
| 2 | 3 | 2 ноктасыннан төньяк-көнбатыш юнәлештә җир кишәрлегенең кадастр чиге буйлап 12,25 м ераклыкка 3 ноктасына кадәр; |
| 3 | 4 | 3 ноктасыннан көньяк-көнбатыш юнәлештә туры почмак астында 16,45 м ераклыкка 4 ноктасына кадәр; |
| 4 | 1 | 4 ноктасыннан көньяк-көнчыгыш юнәлештә җир кишәрлегенең кадастр чиге буйлап 12,25 м ераклыкка 1 ноктасына кадәр. |

Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **характерлы нокталары таблицасы**

| Нокта № | Җирле координаталар системасындагы нокта координаталары (МСК-16) | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 1 | 385881.12 | 1299508.20 |
| 2 | 385886.25 | 1299497.08 |
| 3 | 385901.12 | 1299503.97 |
| 4 | 385896.07 | 1299515.09 |
| 1 | 385881.12 | 1299508.20 |


Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2025 елның 22 декабрендәге 856-П номерлы боерыгына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын
**саклау предметы***

1. Объектның урнашу урыны Болгар шәһәре үзәгендә Пионер һәм Хирург Шеронов урамнары почмагында.
2. Күләм-киңлек композициясе: пландагы конфигурациясе: катлаулы формасы; һәйкәлнең өске ноктасы буенча биеклек билгеләре.
3. Постамент. Куб формалы постамент, кара табигый таш белән тышланган.
4. Өч яшь кешене – кулына каска тоткан бер егетне тезләндергән һәм янәшәдә басып торган кыз белән егетне сурәтләгән сын. Сынның материалы – бетон.
5. Дивар. Җиңүче сугышчыларны һәм мәңгелек утны сурәтләгән күп фигуралы металл панно белән ялтыратылган кызыл гранит белән тышланган дивар. Диварга «Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган якташларыбызга мәңгелек хәтер» дигән язуны формалаштыручы зур металл хәрефләр беркетелгән.

*Саклау предметы комплекслы һәм фәнни тикшеренүләр, реставрация эшләре нәтиҗәләре буенча үзгәртелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы адресы буенча урнашкан «Һәлак булган хәрбиләргә мемориал», 1782 ел, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау предметы таблицасы

| Т/с | Саклау предметы | Төп элементларны фотофиксацияләү/график материаллар |
|---|---|---|
| 1. | Объектның урнашу урыны Болгар шәһәре үзәгендә Пионер һәм Хирург Шеронов урамнары почмагында |   Шартлы билгеләр:<br>- мәдәни мирас объекты<br>1 нче рәсем. Объектның урнашу урыны |
| 2. | Күләм-киңлек композициясе: пландагы конфигурациясе: катлаулы формасы; һәйкәлнең өске ноктасы буенча биеклек билгеләре |   2 нче рәсем. Гомуми күренеше |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Постамент. Куб формалы постамент, кара табигый таш белән тышланган | <br>3 нче рәсем. Көнбатыштан күренеше. Постамент |
| 4. | Өч яшь кешене – кулына каска тоткан бер егетне тезләндергән һәм янәшәдә басып торган кыз белән егетне сурәтләгән сын. Сынның материалы – бетон | <br>4 нче рәсем. Сын |

| | | |
|---|---|---|
| 5. | Дивар. Җиңүче сугышчыларны һәм мәңгелек утны сурәтләгән күп фигуралы металл панно белән ялтыратылган кызыл гранит белән тышланган дивар. Диварга «Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган якташларыбызга мәңгелек хәтер» дигән язуны формалаштыручы зур металл хәрефләр беркетелгән | <br>5 нче рәсем. Җиңүче сугышчыларны һәм Мәңгелек утны сурәтләгән панно<br><br><br>6 нчы рәсем. «Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган якташларыбызга мәңгелек хәтер» язуын формалаштыручы хәрефләр |